КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 октябрь г.Казань № 935

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 20 май, 479 нчы карары белән расланган Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарын ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукленуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукленуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 май, 479 нчы карары белән

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 25 август, 896 нчы; 2023 ел, 21 гыйнвар, 29 нчы; 2023 ел, 23 февраль, 179 нчы; 2023 ел, 14 август, 974 нче; 2024 ел, 7 май, 312 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибенә, 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Субсидияләр турында файдалану мөмкинлеге чикле булган мәгълүмат булып тора һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында урнаштырылмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин